ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл
җирлеге Советы

422756, ТР Әтнә муниципаль районы,
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 34-6-25

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Большеменгерского
сельского поселения
Атнинского муниципального района

422756, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Большой Менгер, улица Советская, 8
тел. 34-6-25

# КАРАР

«02» октябрь 2017 ел. № 58

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартындагы «Җирле референдум турында» 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, 2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 16 номерлы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитеты карары«, 2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 57 номерлы Олы Мәмәнгәр авыл җирлеге Советының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәнгәр авыл·җирлеге Советы карар **бирде:**

1. 2017 елның 19 ноябрenә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2018 елда үзара салым кертү өчен 18 яшькә җиткән, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган Олы Мәңгәр авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 1000 (мең) сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрү белән килешәсезме?:

1. Авыл җирлеге территориясендә җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:

- төзелеш материаллары сатып алу, Олы Мәңгәр, Иске Мәңгәр, Бәхтияр авыллары урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү;

2. Олы Мәңгәр, Иске Мәңгәр, Бәхтияр авыллары территорияләрен төзекләндерү һәм чистарту эшләре алып бару.

ӘЙЕ ЮК»

3. Олы Мәңгәр авыл җирлегенең сайлау комиссияләренә, гамәлдәге законнар нигезендә, «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

4. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны экономияләү очрагында, әлеге акчалар планлаштырылган эшләрне башкару өчен акча җитәрлек булмаган юнәлешләрне финанслауга юнәлтелә.

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру, «Этнә таны» район газетасында бастырып чыгару һәм http://atnya.tatarstan.ru рәсми сайтка урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы — Хисматуллин В.В.